Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ОКТЯБРЬ * 2021 * КАЗАН

10



Рашат НИЗАМИ

БУТАЛЫШ

Яшибез күк эммиграцияләрдә,
Очы-кырые юктыр бу Илнең.
Аңлар өчен тормыш катмарлыгын
Йөз сыналдым, йөз кат бөгелдем.

Гаделлек юк мәгълүм чуар илдә,
Парламентта – буза, зилзилә…
Коеп-коеп барган кануннары
Үзләренә генә мач килә!

Ә күңелдә яктылык аз калды,
Кая бакма – ачы вазгыять.
Фаэтонын җигеп, ил кырыннан
Нигә элдерми соң җәмгыять?

Кечкенәсен тиз укмаштырдылар,
Зур Ватанын югалттылар да.
Мичкәдәге шовинизм дигән
Дары – хәттин ашкан боларда.

Илне корган ветераннар кими,
Пенсионер төште почёттан.
Бәхетеңне сатып алалмыйсың
Базардан йә бетле талчуктан.

Фаҗигагә дучар үз телләре –
Гел торалар аңа бәйләнеп.
Кәсафәте үзләренә кайта
Бумеранг сыман әйләнеп.

Тугандашы аның телен гел
Кыерсыта, имеш, һәрчакта.
Үзеңдәге кече халыкларның
Туган телен буып,
Кереп булмыйдыр ла оҗмахка!

Язучылар язар китабына
Уңай герой таба алмыйлар.
Заманаың болганчык икәнен
Эт-мәчеләр хәтта аңлыйлар.

Кибет, базар, хәтта рәсмилектә
Сүгенүләр керде модага.
Экраннардан, китап битләреннән
Бик еш кына нәҗес сүз ага.

Эш табалмый, ил иләнен таптый
ВУЗ бетергән адәмнәребез.
Лабиринтта капка эзләүчегә,
Адашканга охшаш мәлебез.

Байлар үрчи… Хәерчеләр исә
Мусор бакларында казына.
Кабат әйтәм: зур акчалы канун
Тик элита өчен языла!..

Михаил ЛАРИЧЕВ



ШОМБАЙ

болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел радиодан бер сайлау алды сәясәтчесе зур масштаблы урлаулар өчен чиктән тыш җәза куллану кертергә тәкъдим итте. Гаҗәп, ләкин күп кенә тыңлаучылар моның белән риза булган. Ул гына түгел, кайберләре, Кытайдагы кебек, бу гамәлне телевизордан күрсәтергә тәкъдим иткәннәр. Мин үзем канга сусаучы түгел, әмма өлешчә алар белән риза. Барысы да урлый – губернаторлар, депутатлар, чиновниклар… Ә җәзасы нинди? Миллиардлап урлаганнар, намуссыз рәвештә үзләштергәнне югалтмыйча, шартлы срок алалар…

З. АЙМИЕВ, пенсионер

КАЗАН

Хатка Шомбай ага җавап бирде.

– Әгәр дә без Кытай юлыннан китсәк, телевизордан мәктәптә ремонт ясау өчен акча җыйган укытучыларны атып үтергәнне күрсәтәчәкләр бит…

Илдус МИҢНУЛЛИН

БҮТӘКӘ КҮРКӘНЕКЕ

Хуҗа ук булмасам да, мин
Эшлимен зур урында. –
Суд бинасы төнлә белән
Кала минем кулымда.

Газы кергән, суы килгән,
Бәдрәфе дә бинада.
Картаймыш көнемдә бәхет
Елмайды бит миңа да.

Бүлмәләр зур, җылы, якты,
Кәефләр күтәренке.
Үзем бәләкәй булсам да,
Бүтәкә күркәнеке!

Мине күргәч, аллә өркеп,
Хөрмәт белән дәшәләр.
Әлбәттә, күршеләрем дә
Чүт кенә көнләшәләр.

Зам Мирового судьи, дип,
Хатын да зурлап дәшә.
Миңа сиздерми, эченнән
Үзе көлсә дә гәрчә.

УЗИ түгел, белеп булмый
Аның эчке халәтен.
Юк аппарат белә торган
Хатын-кызның хәйләсен.

Ринат АБЗАЛОВ





Александр АЛЁШИН

Егетләр ярсуы

Узган гасырда яшәгән атаклы мөгаллим фикеренчә, бәхәстә җиңеп чыгуның бердәнбер ысулы – анда катнашмау. Иә уртак тел табу. Ләкин тормышта бөтенесе дә катлаулырак, һәм психология фәнен өйрәнү сәләте дә бар кешегә дә бирелмәгән. Шуңа күрә еш кына уртак фикергә килү өчен кулларны, аякларны, авыр әйберләрне һәм башка үтемле дәлилләрне файдаланырга туры килә. Ә инде бәхәсләшүчеләргә үҗәтлекне хәмер дә өсти икән, бәхәстән хаклык түгел, ике якны да күңелсез нәтиҗәләргә китерүче гади сугышу барлыкка килә.

Менә, мәсәлән, җәйге җылы бер кичтә дүрт татарстанлы исерек дөмбәсләшүләр нәтиҗәсендә, хастаханәдә урын тапкан. Бөтен вакыйгалар да аракы тамчылары кебек охшаш: эчкән, сугышкан, табибка эләккән. 17 яшьлек Казан егете, үзенә ата булырлык яшьтәге ир белән тамак чылатканнан соң, аның тормышка карашлары белән ризалаша алмаган. Яшьлек дәрте өстенлек алган һәм абзыйны башындагы ачык җәрәхәтләр белән реанимациягә алып киткәннәр. Ә Чаллыда кәеф-сафа корганнан соң, ике туган бәхәскә кергән. 55 яшьлек слесарь ныклы дәлил сыйфатында кухняда яткан пычакны файдаланган. Тагын бер урында моның өчен үтүк кулланылган, һәм хастаханә тагын ике бәхәсче белән тулыланган.

Ләкин мондый кискен каршы торулар өй эчендә генә калмый. Исереккә тамашачы кирәк, ә сәхнә булып теләсә нәрсә хезмәт итә ала. Күптән түгел Казанда автобус эчендә шундый хәл булган. Тукталышта салонга ике "салмыш" ир кереп утырган. Гадәти нәрсә шикелле, әмма аларның берсе тәмәке кабызып җибәргән. Пассажирлар ризасызлык белдергәннәр. Сугыш кабынып киткән, нәтиҗәдә, сәрхушләрне автобустан төртеп чыгарганнар, ә тегеләре автобуска ташлар атып, аның тәрәзәсен ватканнар.

Клубларның берсендә исерек бәргәләшү булган. Тамада, кирәгеннән артыграк хәмер йотып, күңел ачып алырга булган – кулына урындык алып, аны кунак ханымнарның берсенә томырган. Гүзәл зат җавапсыз калмаган, мәҗлес алып баручы ягына тәлинкәләр оча башлаган. Кичә, шулай итеп, полиция бүлегендә тәмамланган.

Мөнәсәбәтләрен ачыклаучы исерек бәхәсчеләр, гадәттә, моның өчен урын сайлап тормыйлар. Күптән түгел республика хастаханәсендә каты бәрелеш булып алган. 57 яшьлек казанлы монда инде сугыш җәрәхәтләре белән кергән. Табиблар аның башындагы ярасын ямаганнар. Ә рәткә кереп тә җитмәгән пациент, ярсып, йодрык болгап, табибларга ыргылган. Яралы җәнҗалчыны Росгвардия көчләре белән тынычландырганнар.

Белгечләр илнең ун ел буе айныткычларсыз яшәве нинди мораль һәм матди югалтуларга китергәнен исәпләп караганнар. Җинаятьләрнең өчтән бере исерек затлар тарафыннан эшләнә, алкоголь ел саен 50 мең кешене теге дөньяга җибәрә, ә исерек машина йөртүчеләр катнашы белән булган юл фаҗигаләренең саны бермә-бер арткан. Айныткычларны торгызырга булганнар, ләкин элек анда бөтен шик тудырган гражданнарны тотырган булсалар, хәзер "санаторий"га үз-үзен белмәгән хәлдәгеләрне генә алалар. Моны аңлап була – айныткычлар хәзергә аз, бөтенесен дә сыйдырып булмый. Тик шулай да юнәлеш дөрес якка таба бара...


Бу нәрсәнең бер көтелмәгән ягы бар. Исерек мәҗлесләрдә катнашучылар йодрыкларын үз ирекләре белән болгамыйлар икән. Галимнәр фикеренчә, баш миенең алкоголь тәэсирендә каршы якның үз-үзен тотышын дөрес кабул итми торган өлеше бар икән. Һәм шуның аркасында сәрхушләргә полиция бүлегенә эләккәч, бәрелешкә кучкән кайнар бәхәснең бөтен нечкәлекләрен искә төшереп утырырга туры килә...

Людмила САФИУЛЛИНА



Юрий КУХАРЕНКО


Валерий ТАРАСЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО





• • •

– Мәхмүт, син бу юлы өй эшеңне күпкә әйбәтрәк эшләгәнсең.

– Әти миңа булышудан туктады.

• • •

– Карагыз әле, чибәркәй, сез Инстаграмда матуррак күренәсез.

– Сез дә үзегезнең блогыгызда мондый ук җүләр түгел.

• • •

Тарих дәресендә:

– Людовик Уналтының әтисе кем булган?

– Людовик Унбиш.

– Яхшы. Ә Карл Җиденченеке?

– Карл Алты.

– Ә Франциск Беренченеке? Ник эндәшмисең?

– Ул, мөгаен, ятим булгандыр!

• • •

Йә, ярый, ул карчык ярык тагарак янында калган ди, аның каравы, башта социаль баскычларда рәхәтләнеп йөргән!

• • •

Әфганстанда хакимияткә итәкле һәм сакаллы ирләр килгәч, аларны түземсезлек белән Евровидениедә көтә башлаганнар.

• • •

Хатын-кызлар җиңел алына торган кредит кебек: бик яхшы шартлар, матур рекламалар, бары тик паспорт кына кирәк, соңыннан гомерең буе бурычта.

• • •

11 ел буе мәктәптә укып, ипотека турында да, счётларга түләүне дә, налогларны да белмәгәнмен. Ә менә инфузориянең төзелешен бик яхшы үзләштердем.

• • •

– Өйләнешүебезгә бишенче көн дигәндә ирем үлеп китте.

– Озак интекмәгән икән, мескен!

• • •

Табиб-невролог башы авыртуга зарланып кергән пациенттан сорый:

– Сез кияүдәме?

– Юк.

– Алайса аңламыйм…

• • •

– Киявегез сезгә ничегрәк?

– Әйбәт егет! Вакциналанган гаиләдән!

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Яңа уку елы

– Менә шулай, дуслар, – дип, сүзен башлады мәктәп директоры Гондурас Гарипович. – Яңа уку елы башланды. Шул уңайдан мин Мактау тактасы турында әйтеп китәсем килә.

– Нишләгән безнең Мактау тактасы? – дип аптырап калды укытучылар.

– Нишләгәнме? Аны инде ничә еллар яңартканыбыз юк бит. Сез карагыз, андагы балаларның күбесе мәктәпне тәмамлап китте. Бер үзгәреш юк бит.

– Соң, Гондурас Гарипович, кемне эләргә соң анда? – диде аның урынбасары. – Шулар гына иде бит яхшы укучылардан.

– Кем тикшерә хәзер яхшы укуны?.. Беренче урында спорт белән шөгыльләнү кирәк. Шул күрсәткечләр буенча башка мәктәпләр алда бара. Ә без һаман бер урында таптанабыз.

– Гафу итегез, – дип сүзгә кушылды чит ил телләре укытучысы. – Пандемияне сәбәп итеп, алар мәктәпкә дә килмиләр. Дәресләрен эшләмиләр. Инде чит ил телен өйрәнү турында сүз дә юк.

– Менә шунысы яхшы да инде. Чит ил телен белмәсәләр, димәк, мәктәпне бетергәч, безнең илдә калалар. Кем белгән, бәлки, депутатлыкка да сайланып куярлар. Кемдер депутат була икән, безнең мәктәпне дә онытмас, ярдәм итәр. Ә яхшы укучылардан ни файда? Алар шул инде, берәр институтка кереп, лабораторияләрдә утырып гомерләрен уздырырлар. Безгә дә файда юк.

Тә-әк, тагын кемнәрне куярга була Мактау тактасына? Әти-әниләре зур җирдә эшләсәләр, бизнес белән шөгыльләнсәләр, алардан спонсорлык ярдәме көтәргә була.

Әле бер көнне география дәресендә сезнең макталган яхшы укучыларыгызның берсе мине дәресләргә тотынды. Имештер, күп белә ул. Безнең вакытта ничек иде? Укытучы сүзе һәрвакыт дөрес. Ул ялгышмый. Мин аларга балалар шагыйре Пётр Ильич Чайковский турында сөйләмәкче идем. Ә бу бала миңа: "Гафу итегез, сез ялгышасыз, Чайковский – композитор, ә балалар шагыйре – Корней Чуковский", – дигән була.

– Дөрес әйткән бит инде, – дип үзара пышылдашып куйды укытучылар.

– Ярар, булды, башка сорауларыгыз булмаса, мин сезгә барысын да аңлаттым. Мактау тактасын яңартырга! Бизнесмен балаларын һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрне эзләргә! Ир-тә-гүк!

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: СССРның Әфганстанга бәреп керүендә тагын бер сәбәп – безнең ангар һәм хәрби складлар Калашников автоматлары белән шыплап тулган була. Оборона министры маршал Устинов алардан тизрәк "котылырга" кирәк, дигән икән.

Алмаз Хәмзин: Бәлки, генералитетка байлык кәсебе кирәк булгандыр?

Р. Н.: Кешеләргә шатлык бүләк итә белсәң генә кеше чутында йөрерсең.

А. Х.: Җәмгыятебездә "шатлык" төшенчәсе нык кимеде, шуңа күрә кеше чутында йөрүчеләр азайды сыман...

Р. Н.: Кануннарны бозган кеше – иблис токымыннан булыр.

А. Х.: Бик җитди фикер: ул кануннарны язганнары да шул токымнан булырга мөмкиннәр бит.

Р. Н.: Кеше дөрес юлдан атласын өчен, ярый әле намус сакта тора.

А. Х.: Әмма намус кимеде шул безнең җәмгыятьтә...

Р.Н.: Ходай бүләге көн вә төн – һәркемгә җитәрлек итеп бирелгән.

А.Х.: Кич һәм иртәсен дә өстәсәң, әйбәт булыр.

Р. Н.: Мәхәббәт – сәхнә түре, артистлары – ир белән хатын. (Уен дәвам итә.)

А.Х.: Уен түгел, "семейный подряд" оештырып, акча эшләү бу.

Р. Н.: Картлардан көлмә, үзеңнең дә шул яшькә барып җитәсең бар.

А.Х.: Җитсәләр – ярый да...

Р. Н.: Бабам әйтер иде: "Ачу – алдан, акыл арттан йөри", – дип.

А. Х.: Бабаң ниндилегеңне артыңнан белеп, алдан әйтеп калган.

Р. Н.: Күңелең булдымы, дигәнне, күңелең күкәй салдымы, дисәң – ныграк истә калачак!

А. Х.: Күңелең чеби чыгардымы, дисәң уңышлырак, күзен ит ашыйсың.

Р. Н.: Безнең белән, акылдан бигрәк, язмыш идарә итә түгел микән?

А. Х.: Безнең белән хәзер, акыртып, акчалы даирәләр идарә итә, Рашат дус!











ЭШЛӘНМИЧӘ КАЛГАН РЕМОНТ

Казанда 3 нче номерлы колония башлыгын акча үзләштерүдә тотканнар. Подполковник "утыручы"ларның берсеннән, ремонтка дип, 6 мең сум таләп иткән. Акчаны алгач, хуҗа кеше төзелеш материаллары алу өчен тагын 40 мең сораган, әмма бу юлы эше пешмәгән. Полковникны яклаучылар гаҗәптә: нигә, мәсәлән, балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә ремонтка акча җыярга ярый, ә колониядә – юк?

ОЛЫ ҖАНЛЫ ПРИСТАВ

Алабугада суд приставы булып эшләүче бер ханым кырыс хезмәтенә хас булмаган олы җанлылык күрсәткән. Ул кайбер җәзага тартылган гражданнарга карата эшләрне туктаткан. Кәгазьдә алар төзәтү эшләре сыйфатындагы тиешле җәзаларын алганнар, ә чынлыкта исә киң күңелле пристав аларны эштән азат иткән. Бу үз хезмәтен җиңеләйтү һәм волокита өчен җавап бирмәс өчен эшләнгән. Хәзер ханымга җинаять эше буенча җавап тотарга туры киләчәк.

БДИ КОРБАННАРЫ

КНИТУ-КАИ белгечләренең катгый фикеренчә, абитуриентларны вузга кабул итү кагыйдәләрен үзгәртергә кирәк. Тикшеренүләр барышында галимнәр БДИның уртача баллы керүчеләр арасында университетны уңышлы тәмамлаучылык сәләт иясләрен ачыкларга мөмкинлек бирми, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Кичәге мәктәп балаларының шәхси казанышларына күбрәк игътибар итәргә кирәк, дип саный алар. Башка вузларда эшләүче укытучыларның күбесе шул ук фикердә.

КЫЙММӘТКӘ ТӨШКӘН КҮРЕШҮ

Түбән Камадагы 4 нче колония-поселениедән тоткын качкан. Ул территорияне тәртипкә китерү эшләре вакытында җаен туры китереп, табан ялтыраткан. Качкынны тиз тапканнар, ләкин шул вакыт эчендә ул сөйгән кызы яшәгән Лениногорскига барып җитәргә өлгергән. Моны ул мәгъшукасын бик нык сагынуы белән аңлаткан. Егетнең үзен инде декабрьдә азат итәргә тиеш булганнар, тик хәзер сөйгәненнән башка яшәү вакыты сизелерлек артачак. Ялкынлы хисләр ташкыны өчен прокурор гашыйк йөрәккә тагын ике ел ярым өстәүне таләп иткән.

Вячеслав ШИЛОВның мини-вернисажы







Михаил ЛАРИЧЕВ





Әнвәр ДАВЫДОВ

МОДА МОГҖИЗАЛАРЫ

(Бер шагыйрь хатынының җыры)

Шагыйрь хатыны ниләр күрми? –
Сөйлим сезгә тезеп.
Берзаманны кия иде
Ирем алсу күзлек.
Давыл көнне, буран көнне
Кайта ул елмаеп:
«Тышта кояш балкый!» – ди ул,
Авызын исним – аек!

Ачуымнан агарам мин,
Йөрәгемдә ачу,
Ә ул: «Елмаюың матур,
Битең шундый алсу!»

Өстәлгә бәрәңге куям
Өлгертеп көчкә мин.
Ә ул:
«Каян таптың алмаларның
Кызарып пешкәнен?»
Кызганам да кайчагында,
Бар нәрсәне бутый:
Водопроводтан су бирсәм,
«Татлы сироп бу!» – ди.

Ялварам: «Сал күзлегеңне,
Айнык бул, – дим, – әзрәк!»
Ә ул: «Юк, – ди, – чорыбызга
Дан җырларга кирәк!»

Ә берзаман үзен кичен
Көтә идем өзелеп,
Киңәшмәдән кайтып керде
Киеп кара күзлек.

Сагынганмын. Каршы алам,
Елмаямын шулай.
Ә ул: «Миңа күрсәтәсең
Ник караңгы чырай?»

Тегеләй итәм, болай итәм,
Иркәлимен үзен.
«Юк, – ди, – күрәм, күңлең кара,
Һәм кап-кара йөзең!»

Куям өстәлгә ак ипи,
Йөзем белән ботка.
Ә ул: «Нигә икмәк кара?
Сатучыны – судка!»

Көннәр үтә, җәйге кояш
Балкыта җир йөзен.
Ә ул һаман мыгырдана:
«Ник болытлы бу көн?»

Ялварам: «Сал күзлегеңне,
Ял ит, – димен, – әзрәк!»
Ә ул: «Юк, – ди, – безгә хәзер
Щедрин булу кирәк!»

Нишлисең бит, нишлисең бит,
Тордым инде түзеп.
Тик бер көн кайтты союздан
Киеп зәңгәр күзлек.


Узды гына бусагадан,
Салмады да өстен,
Кычкырып җырлап җибәрде:
«Айлы тө-ө-ө-н, айлы тө-ө-ө-н!»
Биш балабыз карап тора,
Зурлар инде күптән.
Ә ул: «Зәңгәр төндә, җаным,
Зәңгәр күлдә көтәм!»

Инде картлык ерак түгел,
Беләм хәлләремне.
Ә ул: «Ах, – ди, – күзеңдәге
Яшьлек зәңгәрлеге!»

Ялварам: «Сал күзлегеңне,
Оят кирәк әзрәк!»
Ә ул: «Юк, – ди, – безгә хәзер
Лирика бик кирәк!»

Минем хәзер соңгы теләк,
(Буламы соң күпме теләп?
Хәлемне үзем генә беләм!)
Миңа таба тик бер генә
Карар микән гади генә
Кеше күзе белән.

Виктор БОГОРАД



Василий АЛЕКСАНДРОВ



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ



КОВИД ӘЙТЕМНӘРЕ

• Прививка ясатмаган вакцинацияләнгәнгә иптәш түгел.

• Якын дустыңны да метр ярым дистанциядә тот.

• Хәзер куар-кодсыз оҗмахка да кертмиләр.

• Кул кулны юа. Антисептик белән.

• Хатыннарны ул пандемия вакытындагы перчаткалар кебек алыштыра иде.

• Гаҗәпләнүдән авызыңны ачканда маскаңны киеп куй.

Наталья БАХТИНА

Александр БРЮХАНОВ



Түшкәев, кояшлы көннән һәм саф һавадан ләззәт алып, ашыкмыйча гына урам буйлап бара иде. Кинәт көтмәгәндә аның каршында тонык күзле кырынмаган бәндә барлыкка килде:

– Брат, илле сум бир әле...

– Ничек инде – бир? – диде аптырашта калган Түшкәев. – Сез, гомумән, кем буласыз соң?

– Мин – синең сәламәтлегең, – дип җавап бирде бәндә тыныч һәм каты тавыш белән.

– Н-н-ничек? Минем сәламәтлегем?..

– Нәкъ шулай, сәламәтлегең! Ә акча миңа үземне рәткә кертер өчен кирәк...

– Нәрсә башымны катырасыз?.. Нинди сәламәтлек?..

– Аңлатып бирәм – сез кайчан туры килә һәм теләсә нәрсә ашыйсыз, шуңа күрә ашказаныгыз тәртиптә түгел. Спорт белән шөгыльләнмисез – йөрәгегез начар эшли. Күп эчәсез, монысыннан кан тамырлары һәм башка бәлаләр. Өстәвенә, хатыныгыз бар – бу инде баш авыртуның сәбәбе...

– Нинди йөрәк, нинди баш авырту ди ул, ни сөйлисез сез?

– Сез үзегез турында күп нәрсәне белмисез, ә организм тузган, какшаган, – диде ир кеше, Түшкәевнең борыны янында бармагын уйнатып.

– Ә сезнең исемегез ничек соң? – дип сорады Түшкәев сак кына.

– Элек минем исемем Булат иде! Ләкин бу сәламәтлек тәртиптә булган чакта...

– Әйе, ныклы исем...

– Ә хәзер Бәла дип атыйлар.

– Ә... хатын-кызлар белән ничек сезнең? – дип пышылдады Түшкәев.

– Берничек тә тә түгел, – дип кулын болгады Бәла, – аларның да минем белән шулай ук...

– Менә минем дә шундый ук хәл, – диде Түшкәев, башын иеп.

– Ә шулай да син миңа акча бирәсеңме соң? – дип талпынып куйды Бәла. – Вакыт әрәмгә уза...

Түшкәев бер мизгел уйланып торды да, көтмәгәндә тәкъдим ясады:

– Әйдә, аптекага барыйк, һәм мин бөтен кирәк нәрсәне алам – бавырдан, ашказаныннан, баштан...

– Син нәрсә? – дип кабынды Бәла. – Бәлки әле табибка да барасыдыр?..

– Ә, нәрсә? Бөтенесе дә шулай эшли...

– Ә сезнең ишеткәнегез бармы – бездәге даруларның яртысы ялган, ә табиблар авырулардан акча каеру белән генә мәшгуль...

– Шулаймыни? – дип гаҗәпләнде Түшкәев. – Ә нишләргә кала соң?..

– Хәзер авыруларны дәвалау мөмкин түгел, авыртуын гына басып була. Илле сум миңа нәкъ шуның өчен кирәк тә инде...

Түшкәев кесәсен актарып алды.

– Миндә йөзлек кенә...

– Йөз дә ярый, – диде Бәла һәм аны җитез генә эләктереп алды. – Болай булгач авыруларга икеләтә көч белән сугарга була! Ә сезгә мин ныклы һәм озак елларга сәламәтлек телим...

Һәм кичәге Булат-баһадир киң адымнар белән шәраб кибетенә таба атлады.

Илдар НӘФИЕВ



Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Дамир МОРТАЗИН

Тикшерүче

– Гражданин, әйе, әйе, сез... Туктагыз!

– Сезгә ни кирәк? Сез кем?

– Мин – тикшерүче!

– Шулаймыни?..Алай булгач туктыйм.

– Сез юл салымын түләдегезме? ЮХИДИ буенча бурычыгыз юкмы?

– Минем машинам юк бит. Хезмәт хакына гына алып булмый аны, бик беләсегез килсә...

– Ә ничек йөрисез соң сез бакчагызга? Җир өчен вакытында түләмәгәнгә бурычларың җыелмадымы?

– Минем бакчам да юк...

– Карале, бакча да тотмый... Күчемсез милкең бардыр – коттедж, фатир, башкасы?..

– Сез, нәрсә, миннән көләсезме? Мин хрущёвкада яшим – әтиемнән калган.

– Хрущёвкада? Димәк, ЖКХга бурычларың җыелган!

– Юк минем бернинди бурычларым! Менә еллык квитанцияләремне күрсәтәм – алай-болай сорасалар, үзем белән йөртәм...

– Кара син моны, нинди итагатьле! Ярый, икенче төрле итеп тикшерәбез сине. Алиментлар мәсьәләсе ничегрәк? Гаебегезне таныгыз, аерылышкансыз, хәзер качып йөрисез? Ата бурычын үтәмисез?

– Тагын нинди ата бурычы? Өйләнмәгән мин, буйдак...

– Карале, карале, ничек оста урнашкан бу тормышта, хәйләкәр! Андыйлар гадәттә "качып" эшлиләр, хезмәт өчен түләүләрен конверт белән алалар, керемнәрен яшерәләр...

– Бюджеттагыларның нинди кереме булсын?! Бик яшерер идем дә, яшерер нием юк...

– Шулайдыр. Димәк, рәсмиләштерелмәгән митингларга йөрисең, ярамаган чыгышлар ясыйсың, "долой, долой!"

– Аллам сакласын! Андый җирдән әйләнеп үтәм, ә компьютерның миндә гомергә булганы булмады.

– Смартфоның бардыр бит?

– Төймәле...

– Гражданин, ничек оят түгел сезгә! Штрафсыз, бурычсыз яшисез... Менә сезнең кебекләр аркасында бюджетка акча килми... Ярый, үз юлыгызда булыгыз! Ә менә сез, гражданин, әйе, әйе, сез, туктагыз. Мин – тикшерүче!





КОНСЕРВЫ ЙӨГЕ

Түбән Новгород өлкәсенең Дзержинск хат ташучылары үз хезмәт вазыйфаларын саклап кала алганнар. Февраль аенда аларның килешүләренә почта хезмәткәрләрен консервылар, макароннар һәм башка халык кулланышы товарларын сатарга мәҗбүр итеп, үзгәрешләр кертkәннәр. Сатучы ролен башкарырга күпләр риза булмаган, шуның өчен баш тартучыларны эштән азат иткәннәр. Бу консервы эшләре прокуратурага барып җиткән. Хезмәткәрләрне эшкә кире кайтарганнар, аларга мораль яктан зыян күрүләре өчен компенсация түләгәннәр.

ПОРТФЕЛЬ

Уфаның 130 нчы мәктәбендә беренче сыйныф укучысына бүләк ителгән портфелен аздан гына тартып алмаганнар. Күп балалы һәм аз керемле гаилә белешмәләр җыйган һәм аларны мәктәпкә илтеп биргән. 1 сентябрь көнне беренче сыйныф укучысына тантаналы рәвештә портфель тапшырылган. Ә берничә көннән соң, әнисенә шалтыратып, бүләкне кире кайтаруларын үтенгәннәр – өлкән улы май аенда балигъ булган һәм күп балалы гаилә дип саналмый башлаган. Әмма акыл өстен чыккан – район хакимияте карары буенча, портфельне балага калдырганнар.

СУЗЫЛА ТОРГАН МЕТРЛАР

Санкт-Петербургта чираттагы сузыла торган фатир тапканнар. Гади торак мәйданында вакытлыча 3,5 мең мигрант теркәлгән. Чит ил кешеләрен «Позитив Групп» ҖЧҖ теркәгән, тик массакүләм теркәлү вакытында компания бернинди хезмәт эшчәнлеге алып бармаган һәм чынлыкта торакны «килмешәкләргә» тәкъдим итмәгән. «Теремок» һәм аның хуҗасын прокуратура тикшерәчәк.

ТИК-ТОК

Киев мәдәният университетында дөньяда беренче TikTok факультеты ачылган. Оештыручыларның максаты Tiktokны «украиналаштыру, үзе артыннан Украинаның яңа тарихын иҗат итәчәк креатив, амбициоз һәм перспективалы яшьләрне алып бару». «ВКонтакте «һәм» Телеграм»га нигез салучы Павел Дуров Tiktokның кеше акылына тискәре йогынты ясавы турында белдергән иде. Аның фикеренчә, «күпчелек кешеләр үз акылларын дөньяны үзгәртергә мөмкинлек бирүче реаль фактлар белән түгел, ә популяр платформаларда очраклы видеороликлар белән тукландыруны өстен күрә».


Илдар НӘФИЕВ


Виктор БОГОРАД

Мирзаһит тормышыннан

ТЕЛЕМ ӘЙЛӘНМӘДЕ

Әгәр авылда иң намуслы һәм гадел кеше кем дип сорасаң, авылдашлары, һичшиксез, беренче итеп Мирзаһитны атый. Аны яхшы күңелле, туры сүзле булганы өчен яраталар иде. Ә аның кешеләр арасындагы каршылыклар һәм бәхәсләрне җиңел, шаярып хәл итүе, гомумән – аерым нәр-сә. Тик шулай да аның тормышында уңайсызланып искә төшерә торган бер хәл була...

Мирзаһит ул чакта мәктәптә укый иде. Җәйге каникуллар вакыты. Күрше Зәйтүнә әби янына шәһәрдән оныгы Марат кайтып төшә. Мирзаһиттан кечерәк булуына карамастан, ул, бөтен шәһәр малайлары кебек, үз-үзенә кирәгеннән артык ышану, тәкәбберлек белән аерылып тора. Һәм берзаман ул дустына велосипедка утырып колхоз бакчасына барып, алма җыеп кайтырга тәкъдим итә.

– Бәлки, кирәк түгелдер? – ди шикләнеп Мирзаһит. – Урлашу була бит... Сакчысы да бардыр әле, күңелсезлек килеп чыгуы мөмкин.

Тик Марат тынмый.

– Әгәр тотсалар, үзебезнекен түгел, чит исемнәрне атарбыз. Шулай итсәк, әти-әниләрне таба алмаслар һәм әйтер кеше булмас. Мин үзем, мәсәлән, классташымның исемен әйтергә җыенам – аны монда барыбер беркем дә белми.

– Сиңа рәхәт, син шәһәрдән, ә миңа атар исем дә юк! – ди Мирзаһит.

– Нәрсә куркасың – теләсә нинди исем әйт! – дип кистерә Марат.

Бакчага әйләнеч юллар белән китәләр. «Тапмасыннар өчен», – дип аңлата моны Марат. Велосипедларын чокырда калдырып, какшаган койма ярыгыннан бакчага керәләр дә, алма җыярга тотыналар.

Кинәт агачлар артыннан форма кигән кеше килеп чыга.

– Кемнәр бу монда?! – дип җикеренә ул. Мирзаһит белән Марат торган урыннарында катып калалар.

– Урлашабыз, димәк? – дип сорый сакчы. – Исемнәрегез ничек? Әйтегез тиз генә!

– Качмасов Марат, – ди Марат, еламсырап. Мирзаһит, ишеткәненә ышанмыйча, дустына карый.

– Кунак малаемы әллә? Кемгә кайттың? – дип дәвам итә сакчы әңгәмәне.

– Зәйтүнә апа янына, элек ул укытучы иде...

– Ә син кем буласың? – дип сорый сакчы Мирзаһиттан.

«Башка беренче килгән исемне әйтәм... » – дип уйлый Мирзаһит, ләкин үзе дә көтмәгәндә: «Вафин Мирзаһит», – дип әйтеп сала..

Хәзер инде Марат дустына гаҗәпләнеп карый.

– Балта остасы Әхмәтҗанның малаемы әллә? Беләм, беләм... Карыйк әле, өегездә нәрсә әйтерләр микән! – ди сакчы һәм, исемнәрен дәфтәренә язып куеп, малайларны иреккә җибәрә.

Кич белән, өйләрендәге "әңгәмәләр"дән соң, тартудан кызарган колакларын уа-уа, дуслар мәктәп коймасы янындагы бүрәнәләр өстендә очраша.

– Ярый, мин югалып калдым ди – үз исемемне атадым, синнән бит икенче итеп сорадылар, ул арада берәр нәрсә уйлап чыгара алган булыр идең! – ди Марат. – Син бит миннән ике яшькә олырак та әле!

– Ә минем... алдарга телем әйләнмәде, – ди Мирзаһит, кызарып.

Шул көннән башлап дуслар беркайчан да урлашмаска һәм алдашмаска дип сүз куешалар. Чөнки аларның бик теләгәндә дә моны булдыра алмаулары ачыклана.

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ

Валерий ТАРАСЕНКО




Борис СТАРЧИКОВ, 1982 ел.



– Менә төзекләндерелмәгән ишегаллары проблемасын хәл иттек!

Виктор ИГНАТЬЕВ, 1964 ел.



– Миннән башка берничек тә тартып чыгара алмыйлар шул!

КЫТАЙДА

2011 елның җәендә, ТР Дәүләт Советы комитеты рәисе, шагыйрь Разил Вәлиев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе составында, миңа Кытайга гастрольләргә барырга туры килде. Ике Сабан туенда катнаштык, 14 көн дәвамында 30 га якын концерт куйдык. Яхшы каршы алдылар, кунак иттеләр.

Ә бер көнне безне берничә йөз чакрым еракльктагы таулар арасында урнашкан кунакханәгә – табигать кочагына алып бардылар. Җитәкчебез – Турсунтай атлы кеше иде. Ул, ихтирам йөзеннән, алданрак барып җитү уе белән, ашыгыбрак элдертә (исеме дә Турсунтай – яшь тай бит), ә без – аның артыннан. Ни хикмәт, таулар арасында ул күздән югалды. Ниндидер бер авылга кереп, тузанлы юлларда шактый адашып йөрдек. Арттан баручы өч шофер да, шул исәптән, мине утыртканы да юлны белми – беренче барулары. Рәхмәт авыл абзыйларына – дөрес юлны күрсәттеләр.

Барып җиттек. Куй чалдылар, кунак иттеләр, җырлы-биюле уеннар башкардык. Шунда Разил абый халкыбызның "Күбәләгем" дигән җырының сүзләрен бераз үзгәртте дә без аны болай дип җырладык:

"Гармунчылар бик күп алар,
уйный белгәне сирәк,
Үзенә тиң гармунчыны,
күбәләгем-түгәрәгем,
Асыл кошым, сандугачым,
сайлый белергә кирәк".

Мин әйтәм, Разил абый, тагын бер сүзен үзгәртсәк, ничек булыр? Ягъни мәсәлән, "сайлый" урынына "сыйлый белергә", дисәк. Татарстанның халык шагыйре (аңа бу мәртәбәле исем нәкъ Кытайда чакта бирелде) минем белән ризалашты һәм өстәп куйды: "Ярый, түлке мәҗлесләрдә генә, – диде. – Мәҗлесләрнең дә барысында да түгел..."

Хәзер бөтен кеше диярлек "Күбәләгем"не яңа сүзләр белән җырлый. Ә мин үзем моны шәхсән гармунчыларга аерым бер ихтирам билгесе дип кабул итәм. Урысча әйткәндә, мелочь, но приятно...

Ачу-кычулар, юл газаплары онытылды. Ә шулай да саубуллашканда, уены-чыны белән бергә, Турсунтайга багышланган шигыребезне, дөресрәге, фикеребезне әйтеп калдырдык:

– Татар халкы өчен өч кадерле сүз бар: беренчесе – Тукай, икенчесе – Кытай, өченчесе – безне ташлап киткән Турсунтай...

Кирам САТИЕВ

Максим СМАГИН



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр ЛЕВИТИН





• • •

Журналист 120 яшьлек карттан интервью ала.

– Киләчәккә планнарыгыз?

– Язга өйләнергә исәп.

– 120 яшьтәме?

– Мин бер дә ашыкмас идем дә, әти кыстый.

• • •

– Чыннан да курсовойны үзегез яздыгызмы?

– Ә сез чынлап та безнең акчаларны уку бүлмәсен ремонтлау өчен тотасызмы?

• • •

Өч әби эскәмиядә утыра.

– Миңа инде 70, бар тешләрем үземнеке. Тфү-тфү, күз тимәсен.

– Миңа инде 75, чәчләрем яшь вакыттагы кебек куе. Тфү-тфү, күз тия күрмәсен.

– Исегез киткән икән! Менә минем тешләрем дә коелып бетте, чәчләрем дә сирәк һәм чал кергән. Әле яшем буенча да мин сездән өлкәнрәк, шулай булуга карамастан, мин һаман кыз килеш. Тфү-тфү, күз тимәсен.

• • •

– Доктор, сез элек биргән дару миңа бик ярдәм итте!

– Ну нәрсә дип әйтим инде? Кайчагында булгалый...

• • •

– Бабай, син кайчан булса да удалёнкада укыдыңмы?

– Әлбәттә, мәктәп безнең авылдан 5 чакрым иде, җәяү йөрдек.

• • •

– Исәнмесез, сезгә банктан шалтыратабыз. Әйтегез әле, сез кайчан да булса безнең хезмәттән файдаландыгызмы?

– Файдаландым. Янәшәгездән үтеп киткәндә, шәүләмне сезнең витриналарыгызда карыйм.

• • •

– Әйтегез әле, сездә хезмәт хакы әйбәтме?

– Әйе, бик әйбәт! Кибеттәге бәяләр генә начар, хезмәт хакы әйбәт...

• • •

Хәзерге беренче класста укучыларның портфельләре шундый, әйтерсең лә алар теләсә кайсы вакытта гаиләдән китәргә һәм яңа тормыш башларга әзер.



КАРГАЛАРГА ШАТЛЫК...

Хөрмәтле редакция! Карбышев урамындагы 58 нче йорт ишегалды төзекләндерү планына кертелгән иде. Балалар өчен яңа уен мәйданнары да ясадылар – бу алар өчен зур шатлык булды. Тротуарларны рәтләделәр, хәтта чүп контейнерларына хәтле салынган сукмакны да тәртипкә китерделәр. Боларына без бик канәгать, тик менә чүп җыелмасының үзенә никтер кагылмадылар. Бөгелеп сына язган профнастил түбәсе, какшаулы стеналары һәм күгәреп беткән капкачсыз контейнерлары элеккеге рәвештә калды.

Район хакимиятендә моны тулысынча тәртипкә китерү өчен өстәмә финанслау кирәклеген әйттеләр. Ә ул, үзегез беләсез, беркайчан да булмый. Шундый сорау туа: нигә бу эшләрне башта ук төзекләндерү программасына кертми калдырганнар?

Ә хәзергә булганына шөкер кылып яшәргә туры килә. Әлегә бу хәлгә бары тик каргалар, хуҗасыз эт, мәчеләр генә канәгать – яңартылган мәйдан, ишегалларына рәхәтләнеп чүптер-нидер, калдык-постыктыр, чир тараталар.

М. ХӘМИТВӘЛИЕВ

КАЗАН

ШУЛ КИЛЕШ...

Кадерле "Чаян"! "Салават күпере" торак комплексындагы 62 нче номерлы автобусның хәрәкәт итү маршрутына карасаң, ирексездән "әйбәт булсын, дип теләдек, әмма шул килеш калды" дигән әйтем искә төшә.

Август ахырында аның маршрутын үзгәрттеләр. Хәзер ул барлык социаль-әһәмиятле торак җирләрне урап уза, ягъни ике микрорайонны били. Транспортчыларның әйтүе буенча, ул пассажирларга бик тә аңлаешлы һәм уңай. Ә менә кулланучылар өчен, маршрутлар җайлы булса да, автобусларның йөрү интервалларына төшенү кыенлыгы бар. Кайвакыт бер-бер артлы өчәр автобус килә дә, буш килеш китеп бара, ә кайчагында сәгатьләр буе көтеп торасың. Була аларның җыелышып төшке ялга киткән чаклары да һәм паркка, дип, сәбәп тапкан очраклары да...

Телефоннардагы махсус өстәмә – кушымталарда да барлык автобуслар чагылмый кайчак, шуңа күрә автобусларның кирәкле тукталышларга килеп җитү вакыты билгесез. Бөтен нәрсә языла торган гаджетлардан файдалану да уңайсыз һәм уңышсыз. Менә шулай катып-туңып торабыз тукталышларда, аптырагач, юл уңаена теләсә нинди машиналарга утырып китәбез.

"Салават күпере" ТКда яшәүчеләр

КАЗАН

Валерий ТАРАСЕНКО



Эльвира ДЫШАЕВА



Альберт ЯХИНның тууына – 90 ел



Альберт Яхин – *"Чаян" тарихының зур эпохасы. Унҗиде ел дәвамында (1959-1975) ул башта җаваплы секретарь, ә аннары баш редактор булып журналга хезмәт итә. Иҗади шәхес һәм оста оештыручы буларак, сатирик басма тирәсендә сәләтле журналистлар, язучылар, шагыйрьләр, рәссамнардан торган профессиональ команда җыя. Талантлы җитәкче һәм юмор остасын хезмәттәшләре һәм укучылары гына түгел, республика җитәкчелеге дә хөрмәт итә. Ә аның кешелек сыйфатлары турында мондый нәрсә сөйли. Татарстанның партия өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Табиев ярдәме белән Альберт Яхинга дүрт бүлмәле фатир тәкъдим ителә. Ләкин ул аны торакка мохтаҗ булган редакция хезмәткәренә бирә. Ә үзе Гагарин урамындагы гади йортта яши башлый.*

Үзсүзле редакторны эшеннән азат иткәч, ул югалып калмый, милли мәгариф өлкәсендә күренекле галим булып китә. Яхин татар әдәбиятын өйрәтүнең оригиналь ысулын булдыра. Ул берүзе беренче сыйныфтан алып унберенчегә кадәр дәреслекләр язып, аларны бастырып чыгара. Аннан соң үз ысулы буенча ике дистә ел авыл мәктәбендә балалар укыта.

Соңгы көннәренә кадәр Альберт Гатуф улы Гагарин урамындагы «хрущёвка»да яши. Бөек чаянчы һәм галимне шуннан соңгы юлга да озаталар.

ФЕЛЬЕТОН НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ?

Берзаман шулай мине редактор бүлмәсенә чакыртып кертте дә:

– Соңгы вакытта бездә басылган фельетоннар бик тешсез булып чыга. Без кире дип саналган типик геройларны таба белмибез. Ә алар янәшәдә генә яшиләр! Эзлә, тап, күзеннән утлар чәчрәрлек итеп яз әле шундый юньсезләрнең берсен, – диде.

Эзләдем, таптым. Ресторан директоры турында фелье-тон язып китердем.

Икенче көнне редактор чакыртты да:

– Булдыргансың! Бик үткен итеп язгансың. Ришвәт алучы юньсезләрне ссуда бирәсе урынга, тагын да югарырак урынга күтәрүчеләр белән без дә көрәшмәсәк, кем көрәшсен. Менә шулар турында язарга кирәк, – диде.

– Шул турыда бит инде, – дим.

– Анысын шулай, тик ул турыда гына да түгел шул, – диде редактор. – Кичә миңа бер бик танылган артист шалтырата. Кәбиров.

– Ул Кәбиров ресторан директорының ире була инде.

– Анысын беләм. Ләкин ул бәйләнешнең фельетонга һичнинди катнашы юк. Эш шунда ки, әлеге директор хатын әнә шул Кәбиров фамилиясе белән йөри икән.

– Ире булгач, йөрер инде, – мин әйтәм.

Редактор авыр сулап куйды.

– Менә шунысы шәп түгел дә инде. Театрга болай да халык күп йөрми икән. Шуның өстенә андагы бер гаепсез артистның фамилиясе фельетонда да чыккач… абайлап алдыңмы инде ылгышыңны!

– Театр турында язмадым ич мин.

– Аңламагансың. Халык моны укыса, театрга бөтенләй йөрмәячәк бит. Димәк, ни булып чыга инде? Ресторан турында язабыз, ә аңарга бер катнашы булмаган театрга зыян китерәбез. Алмаштыр директорның фамилиясен. Кыз чагындагы фамилиясен куясыңмы, башкасынмы, анысы синең эшең. Фельетон ул төрле яктан уйланганда гына файдалы була.

Икенче көнне мин, Кәбированың кыз фамилиясен белеп, үзгәртеп куйдым.

– Менә хәзер эш башка, – диде редактор. – Материалны үзең тикшердеңме?

– Үзем тикшердем. Ресторанга бардым. Халык белән сөйләштем…

– Халык белән сөйләшеп яхшы иткәнсең. Ә менә рес-торанга баруың турында язу әйбәт түгел.

– Бармыйча ничек тикшерим ди мин аны.

– Хикмәт тә шунда шул. Бармыйча тикшерә алмыйсың. Ә бардым дип яздың исә, укучының ни уйлавы бар? Фельетонист кеше ресторанга эчәргә йөри икән дип уйлаячак.

– Мин бит эчмим. Үзегез яхшы беләсез.

– Мин беләм, башкалар белми. Безнең турыда халыкка начар фикер тудырырга ярамас. Болай ит әле син, икеле-микеле сүзләргә урын калмасын өчен, алмаштыр ул ресторанны. Әйтик, кибет итәсеңме анда, башкамы – анысы синең эшең. Фельетонист үзе кар кебек ак кеше булырга тиеш.

Ресторанны кибеткә үзгәртеп куйдым.

– Менә хәзер бөтенләй була язды, – диде редактор. – Инде героеңны тагын да югарырак урынга күтәргән принципсыз кешеләреңне сызарга кирәк була.

– Ничек сызарга?

– Менә шул шул. Фельетон яза белмибез без, дус кеше. Әзрәк каләм тидердеңме, хәзер бөтен сүзләре сүтелә башлый. Үткен тешле фельетон кирәк безгә! Ә бит кире геройлар безнең янәшәдә генә яшиләр алар. Табарга кирәк шуларны, күзләреннән ут чыгарлык итеп пешекләргә кирәк!

Мидхәт САДЫЙКОВ

Кибер-атака



"Галлактика" колхозында – паника. Компьютерлар сафтан чыккан. Яшел тояклы мең баш сыер нишләргә белми. Су эчәргә дип борын төрткән савытларына су килми. Душка кергәннәре дә шул ук хәлдә. Ятакка сыекча кебек әйбер тамуга, сизгер датчиклар ярдәмендә тиешле механизмнар хәрәкәткә китерелеп, аны шунда ук юдырып, киптереп кую системасы да эшләми. Еларга җитешкән кызыл тырнаклы дүрт оператор кыз аптырашта. Компьютер кнопкаларына баскалап та, суккалап та карыйлар, файдасыз. Югыйсә электр уты да, су да, терлек азыгы да бар бит. Ә бит 4-5 сәгатьтән берсе-берсе утызар литр сөт бирүче сыерларны савар вакыт җитә. Нишләргә? Әлеге хәбәр тиз арада хуҗалык җитәкчесенә, өстәге түрәләргә барып ирешә. Ул тиз арада элек ферма мөдире, бригадир булып эшләгән аксак Барыйны да эзләп таба. Нигә улмы? Төп хуҗа хастаханәдә дәваланганлыктан, мондый ситуациядә эшне ул гына оештырып чыгарга сәләтле. Барый – утны-суны кичкән хезмәт ветераны – гадәттән тыш хәлне бик тиз абайлап ала, шул минутта ук җиңел машинасына утырып фермага җилдерә. Юлда берничә кешегә шалтыратып, хәлне аңлата. Берочтан үгез караучы, элекке көтүче Хәлимнәргә дә туктала.

– Хәлим, сәлам! Әйдә, тиз генә җыен, эш бар, – ди. – Сигезледән үрелгән сырлы саплы чыбыркыңны ал да хәзер үк минем арттан фермага йөгер. Үгезне дә көтүгә чыгарырга туры килер, мөгаен. Калганын шунда аңлатырмын, ди. Үзе ашыга-ашыга, чатанлый-чатанлый машинасына юнәлә.

Элеккеге сыер савучыларга да фермадагы хәл-хәбәрне җиткерәләр.

– Аксак Барый ике әйттергәнне яратмый, үзең беләсең...

Ярты сәгать эчендә авыл халкының кемнең кайда икәнлеге ачыклана. Барый белән бер чорда хисапчы булып эшләгән Вилданга тиз арада базардан кыяр, карлыган сатарга киткән өч хатынны алып кайтырга кушыла.

Балта осталары – шабашниклар белән дә элемтәгә керелә. Эшләреннән бүленеп торып, тиз арада сыерларның җәйге утарларын төзәтеп, яңартып бирүләре сорала.

Шулай итеп, сәгать ярым эчендә ферма каршына утызлап кеше – нигездә, элеккеге колхозчылар – җыелып өлгерә. Тагын өч сәгатьтән барлык сыерлар да савылып, урамга чыгарыла.

Бу мизгелдә сыерларның үз-үзләрен тотышын, кыланышларын карап торсаң, үзе бер тамаша. Чөнки алар туганнан бирле ирек күрмәгән, үгезнең ни икәнен белмәгән мал-туар бит. Шуңа да берәүләре юеш борыннарын сусыл үләннән аера алмый, икенчеләре тирә-юньне күзәтә, муенын сузып мөгрәп ала, аларга саф һава тансык. Өченчеләре койрык чәнчек йөгергән була, тонна ярымлы үгез тирәсендә бөтерелә. Көтүче Хәлим чыбыркысын шартлата-шартлата аларны элеккеге җәйләү урынына таба куа...

Мәшәкатьле көннәр бер-бер артлы уза тора, эшләр әкренләп җайга салына бара дигәндә генә, мал бүлешергә дип, айтишник фермер Фазыл Мофаззаловның Казандагы туганнары кайтып төшә. Ашыгыч рәвештә пайчылар җыелышы үткәрергә булалар. Аксак Барый тегеләргә мәсьәләне бик җентекләп аңлатып та карый – юк инде, туганнары килешми. Имеш, аларның абыйлары гына бу эшне оештырган, һәм бернинди авыл халкының да моңа борын тыгарга хакы юк икән... Шундый кызу бәхәс барган бер мизгелдә "Ым-м-му-у-у!" дигән ят тавыштан халык тынып кала, ул гына да түгел, клуб ишегалды капкасын сытып, үзләренә таба килүче пәһлеван үгезне күреп өннәре алына... Биш-алты секунд эчендә иллеләп пайчыдан торган җыелыш урынында аксак Барый белән Көтүче Хәлим генә торып кала.

Шул көннән мал бүлешергә кайтучыларның да эзе суына, авыл халкының да күңеленә шом керә. Чөнки бу якларда элек-электән үк көтүгә үгезләр ирекле чыгарылган һәм хәзер дә менә... Әле ниндие диген, тау хәтлесе. Сыерлар аның янында бозау кебек кенә. Авыл халкы җәй айларында аннан уттан курыккан кебек куркып яшәде. Әмма ник бер кеше кулына каләм алып берәр кая шикаять язсын. Чөнки барысы да сыер-таналарын шуннан каплатырга тырыша, барысының да тәмле ит-аш ашыйсы килә...

Инде менә ямьле җәй дә, җәйләү чоры да әкрен генә узып бара. Тиздән мал-туарларны кабат фермаларга кайтарыр вакыт җитә. Аксак Барыйга килгәндә, ул сафтан чыккан көннән бирле компьютерлаштырылган ферманы кабат җайга салып җибәрү уе белән янып йөри. Менә ул район мәгариф бүлегендә җитәкчене көтеп утыра, секретарь белән сөйләшә.

– Квартира биреп тә укытучыларны, табибларны кайтара алмыйбыз, абый. Нинди айтишниклар, нинди осеминаторлар кайтсын монда. Районга даны чыккан үгезегез бар бит, ул берүзе әллә ничә белгечне алмаштыра, – ди тегесе.

Барый каты бәрелмәскә тырышып, бераз дәшми утырганнан соң:

– Сеңлем, син миңа университет директорының, әйе, ректоры, Гафурның телефонын гына бир дә, мин китәм. Калганын мин үзем хәл итәрмен. Икенче көнне Аксак Барый Казанга дип юлга кузгала.



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 10 (1911) октябрь 2021

Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 04.10.2021 ел.
Тираж – 4058 Заказ Е-3903


Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

16+

Бәясе ирекле

Уйна да, уйла да!





1. Кияүдәге хатын-кыз белән мәхәббәт куертуның төп мәгънәсе нәрсәдә?

2. Үрнәк булырдай ир дип кемне әйтергә була?

3. Нәрсә ул мәхәббәт?

4. Хатын-кызның кызыксынучанлыгыннан да көчлерәк нәрсә булырга мөмкин?

5. Ялгыз булуыгызны ничек аңларга?

6. Һәрбер коллективның нигезендә ни ята?

7. Гражданлык ни өчен кирәк?

ҖАВАПЛАР

1. Берүк иреннән генә аерыла күрмәсен. 2. Ул гаилә тормышында бөтенесен дөрес эшли, ләкин бәйләнер өчен барыбер берәр сәбәп калдыра. 3. Бу – чишелеш эзләгәндә өченчесе барлыкка килә торган ике билгесезлек тигезләмә. 4. Сөйләшкәндә серне ачып салу теләге генә. 5. Август аен көтегез. Берәү дә ташкабак тәкъдим итмәсә – сез ялгыз. 6. Берәүләр – боера, икенчеләр – куша, өченчеләр – үти. 7. Салымны кемгә түләргә икәнен бутамас өчен.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 9 нчы санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«МӘДИНӘМ, ГӨЛКӘЕМ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
М. НӘРИМАНОВ (Сарман),
Р. САФИН (Балык Бистәсе, Полянка ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Сарманнан


Мәҗит НӘРИМАНОВ!

ТИШЕК КӨПЧӘК

Машина ватыла. Машина йөртүче авария фонаре куеп, капот астында казына башлый. Кинәт арттан кемдер кычкырта. Караса – руль артында яшь кыз утыра.

– Нәрсә торасыз? Әйләнеп узыгыз! – ди ир кеше.

– Ә мин сезнең кайсы якка барасыгызны каян белим? Сезнең поворотник – бер уңга, бер сулга күрсәтеп тора!



Виктор ФЁДОРОВ



Константин МАЛЬЦЕВ

• • •

Юл аша чыгып баручы берәүне машина бәреп ега. Йөртүче аның янына йөгереп чыга һәм иелеп:

– Бәхетегез бар икән, мин – табиб.

Тегесе башын күтәрә һәм әйтә:

– Ә сезнең юк мин – юрист!

• • •

Автосалонда:

– Машина алырга телисезме?

– Әйе. Эшемне алыштырдым, ә анда парковка бик тыгын, кайчагында ишекне дә ачып булмый.

– Яңа машинага нинди теләкләрегез бар?

– Иң мөһиме: түбәсендә люк булсын иде.

• • •

Машина йөртүче – инспекторга:

– Командир, җибәр инде...

Тегесе, документларны актарып:

– Ярамый!

– Ничек инде, ә сигезенче битне ачтыңмы соң?! – ди машина йөртүче.

– Ә-ә-ә, ярый. Хәерле юл...



Ринат АБЗАЛОВ

– Чакырткан идегезме?...



Виталий ПОДВИЦКИЙ

4612750670080